ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
17.02.2020

КАРАР
ПР-25

## «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 16.01.2015 ел, №4-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы һәм 2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның комплекслы программасы нигезендә, җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1) Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турында нигезләмәсен (алга таба – премия) 1 нче кушымта нигезендә;

2) 2 нче кушымта нигезендә премия бирү комиссиясе составын;

2. «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 ноябрендә кабул ителгән «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен премиясе турында" ПР-295 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган
«17» 02.2020 г. №ПР-25
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен" премиясе турында нигезләмә

1. «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты премиясе (алга таба - премия) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында бирелә.

2. Премияне бирү ярты ел нәтиҗәләре буенча елга ике тапкыр башкарыла. Һәр ярты еллык өчен өч премия, һәрберсе өчәр мең сум күләмендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм бюджеттан тыш башка чыганаклар хисабына бирелә.

3.Премия бирү өчен кандидатлар булып Татарстан Республикасында хокук саклау юнәлешендәге халык дружиналары һәм иҗтимагый берләшмәләр реестрына кертелгән Актаныш муниципаль районы халык дружиналары әгъзалары тора.

4. Актаныш муниципаль районы халык дружинасы отряды командиры тарафыннан имзаланган премия бирү өчен кандидатны тәкъдим итү, Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы бүлеге начальнигы белән килештереп, ярты еллыкка кадәр 10 көн кала, составы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана торган комиссиягә җибәрелә: 20 июньгә кадәр һәм 20 декабрьгә кадәр ел саен форма буенча, әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә.

5. Премия бирүгә кандидатлар халык дружиналары отрядлары командирлары тәкъдимнәре буенча комиссия утырышында карала.

6. Комиссия үз утырышларына хокук саклау органнары, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен һәм халык дружиналары отрядлары командирларын чакырырга хокуклы.

7. Премияне бирү турындагы карар комиссия утырышында утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

8. Карар кабул иткәндә түбәндәге категорияләр исәпкә алына:

1) массакүләм чаралар үткәргәндә халык дружинасы әгъзасының катнашуы;

2) дежурлыкка чыгу даимилиге;

3) административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау;

4) җинаятьне ачуда хокук саклау органнарына ярдәм күрсәтү.

Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш уздырылган көннән өч көн эчендә килешүдә катнашкан рәис, секретарь һәм комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланды
«17» 02.2020г. № ПР-15
2 нче кушымта

Премияләр бирү буенча комиссия
составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Нурлыева Ләйсән Фоат кызы | Комиссия рәисе.<br>Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 2. | Газетдинова Шәһриназ Илһам кызы | ТР АМР " ФОРПОСТ" МБУ педагог-оештыручысы |
| 3. | Латипов Назил Назыйф улы | ТР АМР "ФОРПОСТ" МБУ директоры |
| 4. | Нуриев Фәһим Зәкәри улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлегенең җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция начальнигы урынбасары |
| 5. | Иманаев Айдар Илфат улы | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы |